МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.12.2018 г.Казань № 1145

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 24 гыйнварендә теркәлде, № 5404

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү тәртибе турында» 2016 елның 4 октябрендәге 568 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү тәртибе турында» 2016 елның 4 октябрендәге 568 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү тәртибенә кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.12.2018 № 1145 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү тәртибе турында» 2016 елның 4 октябрендәге 568 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә 1.1 пунктта «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны терноэкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 528н номерлы боерыгы» сүзләрен Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Медик-социаль экспертиза буенча дәүләт учреждениеләреннән бирелә торган инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибен һәм аларның формаларын раслау турында» 2017 елның 13 июнендәге 486н номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә 2.3 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Территориаль социаль яклау органы тарафыннан теркәлгән гаризаның күчермәсе аны теркәүгә алган көнне, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлеге хезмәткәре тарафыннан тикшерү актын төзү буенча әзерлек эшләрен уздыру өчен, Татарстан Республикасының халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә тапшырыла.»;

3 бүлектә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлеге хезмәткәре гаризаны теркәүгә алган датадан башлап ике календарь көне узганчы гражданинга яки аның законлы вәкиленә гаризада күрсәтелгән ысул белән тикшерү актын төзү һәм бирү өчен инвалид баланың гаризада күрсәтелгән яшәү урыны буенча эш көннәрендә һәм халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең эш сәгатьләрендә гаиләгә килү датасы һәм вакыты турында хәбәр җиткерә.»;

3.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Тикшерү акты инвалид баланың яшәү урыны буенча гаризаны теркәгән датадан башлап биш календарь көненнән соңга калмыйча халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлеге хезмәткәре һәм территориаль социаль яклау органы җитәкчесе белән берлектә гражданин яки аның

законлы вәкиле тарафыннан тапшырылган, алар турында мәгълүматлар тикшерү актында күрсәтелә торган, шулай ук инвалид баланы тернәкләндерү яки абилитацияләүнең хосусый программасындагы товарны сатып алу көненә гамәлдә булган, «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча медик-социаль экспертизаның баш бюросы» ФКУ бирелгән документлар һәм барлыгы тикшерелә торган товарның сатып алынуын раслаучы документлар нигезендә төзелә.».